**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**29 сентябрь, 2023 ел** **№ 323**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы беренче өлешенең 20 пункты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 23-25, 28 статьялары, Чернышевка авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлауларның 2023 елның 31 августындагы беркетмәләре, Чернышевка авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында 2023 елның 31 августындагы бәяләмә, Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Кушымтада бирелгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертүне расларга.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

Совет рәисе,
муниципаль районы Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында» карарына материаллар белән территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында УИН 9262247402020304202307071 танышырга мөмкин.